**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«22» сентябрь 2016 ел Яңа пос. № 16

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге 230 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен тормышка ашыру максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «8» декабрь 2015 ел, № 230 карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

3. Программаны финанслау:

Программаны финанслауның гомуми күләме 120 мең сум тәшкил итә

Муниципаль бюджетлардан финанслар белән идарә итүче - авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе.

Тиешле финанс елына бюджетларны формалаштырганда финанслауның күрсәтелгән күләмнәре төгәлләштерелергә тиеш.

Әлеге финанслау күләмнәре тиешле финанс елына бюджетларны формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкин булган саен район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе М.Г. Фазылҗанов